ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 9 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 645**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү хакында» 2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Балигъ булмаганнарга никотин булмаган продукцияне, никотинны илтеп җиткерүнең электрон системаларын һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2020 елның 19 ноябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү хакында» 2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар Кодексының «2.16 статья - балигъ булмаганнарга никотин булган продукцияне, никотинны илтеп җиткерүнең электрон системаларын сатуны тыю бозылу, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәке булмаган никотин булган продукцияне куллануга җәлеп итү» статьясын каралган административ хокук бозулар составлары исемлегеннән төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат сайтында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе О.В. Заглядовага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов